**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап (ответы)**
**2020-2021 учебный год**
**9 класс**

Олимпиада состоит из 8 заданий. Внимательно ознакомьтесь с заданиями и выполните их. Рекомендуем выполнять задания последовательно, но принимаются и ответы, написанные в произвольном порядке.
Ответы можно вводить на компьютере в текстовом редакторе (только используйте татарские буквы) или писать от руки на бумаге. В случае написания ответов от руки необходимо прикрепить фото или скан-копию ответов.

**I. Сүзтезмәдәге һәр сүзне антонимы белән алыштырып языгыз. /** Замените каждое слово словосочетания антонимами. *(10 баллов. За каждый правильный вариант по 1 баллу.)*
Шатлыклы очрашу; мактанчык хуҗа; төнге тынлык; батырлык белән горурлану; кызларның җиңүе; кар туктады; күп керемле; елдан- ел арту; тырышлык өчен мактау; саран абый.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1) **Шатлыклы очрашу** - кайгылы аерылышу.
2) **Мактанчык хуҗа** - тыйнак кунак.
3) **Төнге тынлык** - көндезге шау-шу.
4) **Батырлык белән горурлану** - куркаклыктан хурлану (оялу).
5) **Кызларның җиңүе -** малайларның (егетләрнең) җиңелүе.
6) **Кар туктады** – яңгыр башлана.
7) **Күп керемле - аз** чыгымлы.
8) **Елдан- ел арту** - көнән-көн кимү.
9) **Тырышлык өчен мактау -** ялкаулык өчен хурлау (сүгү, битәрләү).
10) **Саран абый** - юмарт апа.

**II. Ябык иҗекле сүзләрдән генә торган (10 сүзле) 1 җөмлә языгыз. /** Напишите предложение из 10 слов, где каждое слово состоит только из закрытых слогов. *(10 баллов. За каждое правильное слово по 1 баллу.)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Кышның салкыннарын көткәнлектән, барлык сыйныфташлар алдан хәстәрлек күргәннәр, туннар алганнар**.**

**III. Мәкальләрне дәвам итеп языгыз. /** Подумайте и напишите окончание пословиц. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла.)*

Татлы тел тимер ...; Теле барлар халык булган, ...; Хайванны азык белән, кешене ...; Надан белән бәхәсләшү – ...; Каләм белән язганны ...

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
1) Татлы тел тимер ...; капканы ачар.
2) Теле барлар халык булган, ... теле юклар балык булган.
3) Хайванны азык белән, кешене ... тел белән өйрәтәләр.
4) Надан белән бәхәсләшү – ... үзе наданлык билгесе.
5) Каләм белән язганны ... балта белән юна алмассың.

**IV. Тотрыклы сүзтезмәләрнең мәгънәләрен аңлатып языгыз.** / Объясните значения устойчивых выражений. *(10 баллов. За каждый ответ по 2 балла.)*
Ерык авыз; сөмсере коелган; ике чабата бер кием; тозакка эләгү; типсә, тимер өзәрлек.

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
**Ерык авыз -** шат, һәрчак позитив кеше.
**Сөмсере коелган -** кәефсез, борчулы, күңелсез.
**Ике чабата бер кием** – бер-берсенә эш-гамәлләре белән охшаш кешеләр турында.
**Тозакка эләгү** – кемнең дә булса зарар китерү өчен алдан эшләнгән хәйлә, мәкеренә тап булу.
**Типсә, тимер өзәрлек** – көчле, егәрле.

**V. Түбәндәге схемага туры килгән җөмлә уйлап языгыз, аның төрен билгеләгез.** / Придумайте предложение по данной схеме. Укажите его тип. *(15 баллов. 5 баллов - за верное определение + 10 баллов – за правильный пример.)*



**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Бу – катнаш кушма җөмлә.
Мәсәлән, Мартлар җитеп, карлар эри башласа, беренче чәчкәләр күренер, тиздән инде колхозда кыр эшләре дә башланып китәр. (Ә.Еники)

**VI. Төп ике сүзенә таянып, мәкальләрне торгызыгыз.** / Вспомните и составьте по двум данным словам пословицы *(10 баллов. За каждый ответ по 2 балла.)*
**Сүз- күз; җыр- юлдаш; акыл- тел; китап- чишмә; кунак-тыйнак.**

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
Сөйләсәң **сүз ч**ыга, төртсәң **күз** чыга; **Җыр** - кешенең **юлдаш**ы; **Акы**лы кысканың **теле** озын; **Китап**- белем **чишмәсе**; **Кунак** булсаң **тыйнак** бул.

**VII. Татар телендә кулланыла торган бәйлекләр турында ниләр беләсез? Аларның 1) вазифалары; 2) төрләре турында языгыз; 3) мисаллар китерегез. /** Что Вы знаете о послелогах в татарском языке? Напишите об их: 1) функциях; 2) видах; 3) приведите примеры. *(15 баллов. Каждый критерий оценивается 5 баллами.)*

**Пример ответа:**
**Үрнәк җавап:**
**1) Вазифалары:** Бәйлекләр – ияргүче кисәк белән ияртүче кисәк, иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасында төрле бәйләнешләрне белдерәләр, аларны үзара бәлиләр.
2) **Төрләре**: Бәйлекләр үзләреннән алда килгән сүзнең нинди дә булса килештә килүләрен таләп итәләр һәм 3 төркемгә бүленәләр.
*Баш килешне* сораучы бәйлекләр: кебек, белән, сыман, төсле, аша, өчен.
*Искәрмә:* баш килешне сораучы бәйлекләр үзләреннән алда килгән алмашлыкның иялек килешендә торуын таләп итәләр: аның төсле, сезнең белән.
*Юнәлеш килешен* сораучы бәйлекләр: кадәр, хәтле, тикле, чаклы, таба, күрә, каршы.
*Искәрмә:* кадәр, чаклы, хәтле, тикле бәйлекләре башкилештәге исем белән дә килә алалар. Бу вакытта алар чагыштыруны белдерәләр. Юнәлеш килешендәге сүзләр белән килгәндә чикне күрсәтәләр.
*Чыгыш килешен* сораучы бәйлекләр: башка, бирле, соң, элек.
3) **Мисаллар:** Баш килешне сораучы бәйлекләр: Әни белән кибеткә бардык, Дустым өчен акча түләдем.
**Юнәлеш килешен сораучы бәйлекләр:** Дәрескә кадәр сөйләшеп алдык. Өйгә таба кайтырга чыктык.
**Чыгыш килешне сораучы бәйлекләр:** Дәресләрдән соң мин түгәрәккә киттем. Марттан бирле кояшлы көннәр артты.

**VIII. "Телләр белү ни өчен кирәк?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз. 2дән ким булмаган дәлил китерегез. /** Напишите сочинение (не менее 70 слов), ответив на вопрос "Зачем нужно знать языки?". Приведите не менее 2 довода – примера. *(20 баллов)*

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге.*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы.*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге.** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана: | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | – логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы.** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык.*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше.** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән. | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык. | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше.** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык. | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше.** | |
| | Грамматик хаталары юк. | 2 |
| | 1–2 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык. | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше.** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар. | 2 |
| | **2–3** хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык. | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше.** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк. | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк). | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше.** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл.** | | **20** |